**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы
**КАРАРы**

2023 елның 07 июне № 30 Урыссу ш.т.п.

2023 елда Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” Уставы нигезендә, Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. 2023 елда эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә.Шәфигуллин